ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

05.03.2021 ел Баулы шәһәре №28

«2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында халыкны наркотиклаштыруны профилактикалау» муниципаль программасын раслау турында

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында наркотикларны законсыз тарату һәм медицина максатларыннан тыш куллануның масштабларын киметү максатларында Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында халыкны наркотиклаштыруны профилактикалау» муниципаль программасын расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче И.И. Гозәеров

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 5 мартындагы
28 номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

«2021-2025 елларга Татарстан Республикасы
Баулы муниципаль районында халыкны
наркотиклаштыруны профилактикалау»
муниципаль программасы

ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программа исеме | «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында халыкны наркотиклаштыруны профилактикалау» муниципаль программасы (алга таба – Программа) |
| Программага заказ бирүче | Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты |
| Программа координаторы | «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының яшьләр эшләре бүлеге» МКУ |
| Программаны эшләүчеләр | «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының яшьләр эшләре бүлеге» МКУ,<br>«Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ;<br>«Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәдәният бүлеге» МКУ;<br>«Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының спорт һәм туризм үсеше бүлеге» МКУ;<br>Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Баулы муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге;<br>Россия Эчке эшләр министрлыгының Баулы районы буенча бүлеге;<br>«Баулы үзәк район хастаханәсе» ДАССУ |
| Программа максаты | Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында законсыз наркотиклар тарату һәм аларны медицина максатларыннан тыш куллануның масштабларын киметү |
| Программа бурычлары | - наркотикларның законсыз әйләнешенә каршы көрәш буенча хокук саклау органнарының көчләрен активлаштыру;<br>- наркомания белән авыручыларны дәвалауның һәм медик- |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | психологик реабилитацияләүнең нәтиҗәлелеген арттыру;<br>- наркотиклар куллануны туктаткан һәм аларга бәйле затларга социаль-психологик ярдәм күрсәтү системасын формалаштыру;<br>- яшүсмерләрдә һәм яшьләрдә сәламәт яшәү рәвеше алып баруга мотивация формалаштыру;<br>- Баулы муниципаль районында наркотикларга каршы профилактик эшне мәгълүмати тәэмин итү системасын үстерү. | | | |
| Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары | 2021-2025 еллар | | | |
| Еллар һәм чыганаклар буенча бүлгәләп, программаны финанслау күләмнәре | Ел | Күздә тотылган акча, мең сум | | |
| | | учреждение | муниципаль район бюджеты | Бюджеттан тыш чыганаклар |
| | 2021 | «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының яшьләр эшләре бүлеге» МКУ | 5 000,0 | - |
| | | «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ | 11 000,0 | |
| | | «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәдәният бүлеге» МКУ | 5 000,0 | |
| | 2022 | «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының яшьләр эшләре бүлеге» МКУ | 5 000,0 | - |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ | 11 000,0 | |
| | | «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәдәният бүлеге» МКУ | 5 000,0 | |
| | 2023 | «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының яшьләр эшләре бүлеге» МКУ | 5 000,0 | - |
| | | «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ | 11 000,0 | |
| | | «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәдәният бүлеге» МКУ | 5 000,0 | |
| | 2024 | «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының яшьләр эшләре бүлеге» МКУ | 5 000,0 | - |
| | | «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль | 11 000,0 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | районы мәгариф бүлеге» МКУ | | |
| | | «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәдәният бүлеге» МКУ | 5 000,0 | |
| | 2025 | «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының яшьләр эшләре бүлеге» МКУ | 5 000,0 | - |
| | | «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ | 11 000,0 | |
| | | «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәдәният бүлеге» МКУ | 5 000,0 | |
| | Барлыгы: | | 105 000,0 | - |
| | Программаны финанслауның гомуми күләме 105 000,0 мең сум тәшкил итә, шулардан:<br>105 000,0 мең сум җирле бюджет акчалары.<br>Искәрмә: Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм тиешле дәрәҗәләрдәге бюджетларны тиешле елга һәм план чорына формалаштыруны исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертергә, шулай ук уртак финанслауга программа чараларын федераль һәм республика бюджетларыннан акча бүлеп бирергә тиеш. | | | |
| Программаның максатларын һәм бурычларын | Программаны тормышка ашыруның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеге наркотиклар кулллануның, наркомания белән авыруның, наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр | | | |

| | |
|---|---|
| (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторларын) тормышка ашыруның көтелә торган ахыргы нәтиҗәләре һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | кулլануның, наркотикларның законсыз әйләнешенә бәйле җинаятьчелек дәрәҗәсенең, наркотиклар куллануның тискәре нәтиҗәләре турында халыкның хәбәрдарлыгын арттыруда чагыла.<br>Программаны гамәлгә ашыруның төп нәтиҗәләре:<br>- Үз вакытында чаралар күрү өчен, Баулы муниципаль районында бу өлкәдәге вәзгыятьнең үсеш динамикасы турында тулы мәгълүмат алу;<br>- наркотиклаштыруны профилактикалау һәм наркотикларның законсыз әйләнешенә каршы тору өлкәсендә белгечләрнең һөнәри компетенциясен күтәрү (гомуми белем бирү мәктәпләренең класс җитәкчеләрен һәм психологларын, мәдәният учреждениеләреннән социомәдәният өлкәсе белгечләрен, яшьләр эшләре һәм спорт учреждениеләре белгечләрен, участок социаль ярдәме хезмәте хезмәткәрләрен, иҗтимагый һәм дини оешмалар вәкилләрен укыту);<br>- Яшүсмерләр һәм яшьләр арасында сәламәт яшәү рәвеше алып баруга, психоактив матдәләр кулланудан баш тартуга мотивация формалаштыру;<br>- наркотиклар куллануны туктаткан кешеләргә социаль-психологик ярдәм күрсәтү системасын киңәйтү, шул исәптән аларны эшкә урнаштыруда ярдәм итү;<br>- наркотикларга бәйле кешеләр өчен мотивацион, дәвалау һәм реабилитация программаларын камилләштерү;<br>- наркотиклар контрабандасын чикләү, наркоҗинаятьчелекнең оешкан формаларына каршы тору һәм наркобизнесның икътисадый нигезләрен какшату буенча хокук саклау органнары эшен активлаштыру. |

## I. Программа хәл итүгә юнәлдерелгән проблема

Баулы шәһәре Урта Азия белән Россиянең Европа өлеше транспорт магистральләре кисешү үзәгендә урнашкан.

Районда нарковәзгыятькә Бөгелмә шәһәренең якынлыгы зур йогынты ясый, аның аша Әфганстан, Пакистан, Иран, Төркия, Кавказ арты, Украина, Балтыйк буе һәм Белоруссия республикаларыннан транзит юллар уза, аннан, нигездә, Бөгелмә шәһәренә тимер юл транспорты белән наркотик чаралар керә.

Бүген наркотиклар куллану иҗтимагый проблемага әйләнде. Баулы муниципаль районында “наркомания” диагнозы белән исәптә 45 кеше тора, шуларның берсе балигъ булмаган кеше, “токсикомания” диагнозы белән 2 кеше исәптә. "Зарарлы нәтиҗәләр белән наркотик чаралар куллану" диагнозы белән профилактик исәпкә 29 кеше тора. "Зарарлы нәтиҗәләр белән пычрак чаралар куллану" диагнозы белән исәптә торучы кешеләр юк.

Баулы муниципаль районында халыкның наркотиклар куллануына һәм аларның законсыз әйләнешенә каршы максатчан эш Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2016 елның 30 мартындагы 69 номерлы карары белән расланган

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында 2016-2020 елларга халыкны наркотиклаштыруны профилактикалау программасы нигезендә алып барылды.

Күрсәтелгән программа нигезендә:

- халыкны наркотиклаштыруга каршы тору чараларының нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән берничә документ эшләнде;

- яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең социаль-позитив ялын оештыру өчен яңа секцияләр һәм түгәрәкләр ачуга җитди игътибар бирелә;

- тематик акцияләр, марафоннар үткәрелә, басма массакүләм мәгълүмат чараларында материаллар бастырып чыгарыла;

- эштә наркотикларга каршы эчтәлекле күрсәтмә агитация чаралары файдаланыла: плакатлар, брошюралар һәм башкалар;

- наркотик матдәләр кулланучы затларны ачыклау нәтиҗәлелеген арттыру өчен шартлар тудырыла;

- наркотик матдәләр куллануга һәм аларның законсыз әйләнешенә каршы көрәш бүлекчәләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге артты һәм хокук саклау органнарының матди-техник базасы ныгыды;

Наркоманияне нәтиҗәле профилактикалауны оештыру мөһим юнәлеш булып тора. Районның уку йортлары методик материал белән тәэмин ителгән, халыкның төрле катлаулары өчен белем бирү проектлары һәм программалары кертелә.

Күрелгән чараларга карамастан, наркомания проблемасы беренче урыннарның берсенә чыга һәм халыкның сәламәтлегенә һәм илкүләм иминлеккә глобаль куркыныч булып кала. Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр законсыз әйләнеше өлкәсендә Россия Эчке эшләр министрлыгының Баулы районы буенча бүлеге тарафыннан ел саен РФ Җинаять кодексының 228 нче маддәсе буенча җинаять эшләре ачыклана һәм тикшерелә, шулай ук РФ КоАП 6.9 нчы маддәсе буенча административ хокук бозулар ачыклана.

Әлеге Программа кысаларында наркомания таралуга каршы нәтиҗәле чараларны тормышка ашыру буенча эшне арттыру планлаштырыла.

Программаны эшләгәндә наркотиклар һәм аларның законсыз әйләнешенә каршы тору буенча республика тәҗрибәсе, Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары тәкъдимнәре, хезмәткәрләрнең гамәли эшчәнлеге исәпкә алынды.

Массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләүгә аерым игътибар бирелә. Наркомания белән көрәш һәм сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау мәсьәләләре буенча даими рубрикалар алып барыла, эчке эшләр бүлегенең оператив сводкалары даими рәвештә урнаштырыла. Районда физик культураны һәм спортны үстерүгә, спорт корылмаларының матди-техник базасын ныгытуга зур игътибар бирелә. Укучы һәм авыл яшьләре арасында мәктәп һәм район ярышлары уздырыла.

## II. Программаның төп макстлары, бурычлары, тормышка ашыру сроклары

Программаның максаты - Татарстан Республикасының Баулы муниципаль районында наркотикларны законсыз тарату һәм законсыз куллану масштабларын киметү.

Программаның максатына ирешү өчен түбәндәге бурычларны үтәү таләп ителә:

наркотикларның законсыз әйләнешенә каршы көрәш буенча хокук саклау органнарының эшен арттыру;

наркотикларга бәйле кешеләр, аларның туганнары белән психотерапевтик эш алып бару системасын камилләштерү;

халыкта сәламәт яшәү рәвеше формалаштыру һәм наркотиклар куллануга тискәре мөнәсәбәт тудыру;

балалар һәм яшьләрне физик культура һәм спорт буенча түгәрәкләргә системалы дәресләргә җәлеп итү өчен шартлар тудыру, волонтерлык хәрәкәтен үстерү;

наркотикларга каршы эшчәнлекне оештыру, норматив-хокукый һәм методик тәэмин итүне камилләштерү.

Программа бурычларын хәл итү өчен түбәндәге чараларны тормышка ашыру каралган:

наркотикларның законсыз әйләнешен чикләү буенча хокук саклау органнары эшенең нәтиҗәлелеген күтәрү;

психоактив матдәләрне легаль булмаган куллануга юл куя торган затларны дәвалау һәм реабилитацияләү системасын үстерү һәм камилләштерү;

халык, шул исәптән балалар һәм яшьләр арасында сәламәт яшәү рәвеше формалаштыру;

наркотикларга каршы эшчәнлекне оештыру, норматив-хокукый һәм методик тәэмин итүне камилләштерү.

Программа чараларының нәтиҗәлелеген бәяләү өчен түбәндәге күрсәткечләрдән файдаланырга тәкъдим ителә:

наркоҗинаятьләрнең гомуми санынннан тикшерелгән авыр һәм аеруча авыр җинаятьләр өлеше;

ачыкланган һәм теркәлгән наркомания белән авыручылар саны;

наркотикларга каршы юнәлдерелгән ата-аналар программалары белән колачланган ата-аналар өлеше;

балалар һәм яшьләрнең гомуми санында түгәрәкләрдә, физик культура һәм спорт, волонтерлык эшчәнлеге белән даими шөгыльләнүче балалар һәм яшьләр өлеше.

Программаны гамәлгә ашыру срогы 2021 - 2025 елларга (5 этапта) исәпләнгән:

1 этап - 2021 ел;

2 этап - 2022 ел;

3 этап - 2023 ел;

4 этап - 2024 ел;

5 этап - 2025 ел.

## III. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Финансирование мероприятий, связанных с реализацией настоящей Программы, осуществляется за счёт ассигнований, предусмотренных на соответствующие цели в бюджете Бавлинского муниципального района на соответствующий финансовый ел.

Әлеге Программаны тормышка ашыруга бәйле чараларны финанслау тиешле финанс елына Баулы муниципаль районы бюджетында тиешле максатларда каралган ассигнованиеләр исәбенә гамәлгә ашырыла.

| | 2021 ел мең сум. | 2022 ел мең сум. | 2023 ел мең сум. | 2024 ел мең сум. | 2025 ел мең сум. |
|---|---|---|---|---|---|
| Җирле бюджет | 21 000,0 | 21 000,0 | 21 000,0 | 21 000,0 | 21 000,0 |
| Барлыгы: | 21 000,0 | 21 000,0 | 21 000,0 | 21 000,0 | 21 000,0 |

## IV. Программаны тормышка ашыру механизмы

Программаның үтәлешенә гомуми контроль Баулы муниципаль районында наркотикларга каршы комиссия тарафыннан тормышка ашырыла, аның функцияләренә програма чаралары буенча күрсәткечләрне төгәлләштерү, Программаны гамәлгә ашыру механизмы һәм башкаручылар составы керә.

Программаның үтәлешен тикшереп тору Баулы муниципаль районы Башкарма комитетына йөкләнә.

Программаны башкаручылар Баулы муниципаль районы Башкарма комитетына билгеләнгән формада чаралар үтәлеше турында квартал саен хисаплар тапшыралар.

Баулы муниципаль районында наркотикларга каршы комиссиясе утырышында Баулы муниципаль районы башкарма комитеты Программаны гамәлгә ашыру һәм финанс чараларыннан файдалануның нәтиҗәлелеге турында хәбәр итә.

## V. Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү

Программада каралган чараларны гамәлгә ашыру түбәндәге мөмкинлекләр бирәчәк:

- балалар һәм яшүсмерләрдә наркотикларга каршы мөнәсәбәт формалаштыру;
- җәмгыятьнең наркотикларга каршы юнәлешен көчәйтү;
- наркотик матдәләрнең законсыз әйләнешен чикләү буенча хокук саклау органнары эшенең нәтиҗәлелеген арттыру.

## VI. Программаны гамәлгә ашыруны тикшереп торуны оештыру

Программаның үтәлешен Баулы муниципаль районы башкарма комитеты тикшереп тора.

Ел саен Баулы муниципаль районында Наркотикларга каршы комиссия утырышында Программаның үтәлеше турында хисап тыңлана.

Программа чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә наркомания таралуына китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны ачыклау өчен наркоситуацияне даими мониторинглау системасы җайга салыначак; наркомания проблемалары белән шөгыльләнүче барлык ведомстволарның көчләрен берләштерү исәбенә наркотиклар кулланучы затларны иртә ачыклау гамәлгә ашырылачак.

## VII. «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында халыкны наркотиклаштыруны профилактикалау» муниципаль программасын тормышка ашыру чаралары

| № | Чара исеме | Башкару | Үткәрү урыны | Оештыручылар |
|---|---|---|---|---|

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| п/п | | сроклары | | |
| 1. | Гомуми белем бирү учреждениеләрендә яшүсмерләр арасында зарарлы гадәтләргә мөнәсәбәтне өйрәнү максатында анкетлау | Ел дәвамында | Белем бирү учреждениеләре | «Яшьләр дөньсы» КПЯҮ МБУ |
| 2. | Наркоманияне профилактикалау буенча заманча технологияләр кертү | гыйнвар | «Милосердие» үзәге | «Милосердие» үзәге |
| 3. | «Күңелле зарядка» флешмобы үткәрү | гыйнвар | Октябрь мәйданы | «Яшьләр дөньсы» КПЯҮ МБУ |
| 4. | Россия Эчке эшләр министрлыгының Баулы районы һәм мәгариф бүлеге белән берлектә наркотик чаралар куллануга тартылган балигъ булмаганнарны ачыклау чараларын үткәрү, аннары балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенә язма мәгълүмат бирү. | Ел дәвамында | «Баулы үзәк район хастаханәсе» ДАССУ, Россия Эчке эшләр министрлыгының Баулы районы бүлеге | психиатр, нарколог, гомуми практика табиблары |
| 5. | ФАП медицина хезмәткәрләре белән «Хәзерге этапта наркомания мәсьәләләре» дәресләре үткәрү | Ел дәвамында | «Баулы үзәк район хастаханәсе» ДАССУ | табиб-нарколог |
| 6. | Табиблары белән «Гомуми медицина практикасында наркоманиядән интегүче затларны ачыклау» дәресләре үткәрү | Ел дәвамында | «Баулы үзәк район хастаханәсе» ДАССУ | табиб-нарколог |
| 7. | 9-11 сыйныф укучыларының ата-аналары белән наркоманияне профилактикалау мәсьәләсе буенча очрашулар үткәрү | Ел дәвамында | белем бирү учреждениеләре, авыл клублары | участок педиаторлары, табиб-нарколог, фельдшерлар |
| 8. | Балалар өчен наркотик чаралар куллануның зарары турында лекцияләр, әңгәмәләр үткәрү | Ел дәвамында | белем бирү учреждениеләре | район педиаторы, табиб-нарколог |
| 9. | Гомуми белем бирү | I квартал | белем бирү | «Яшьләр дөньсы» |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | учреждениеләрендә кешенең зарарлы гадәтләре турында яшүсмерләр белән әңгәмә үткәрү | | учреждениеләре | КПЯҮ МБУ |
| 10. | "Ышаныч телефоннары" эшенең үтемлелеген һәм нәтиҗәлелеген арттыру, буклетлар тарату | февраль | «Милосердие» үзәге | «Милосердие» үзәге |
| 11. | Табиблар белән наркоманияне профилактикалау буенча «түгәрәк өстәл» артында очрашулар оештыру | март | белем бирү учреждениеләре | табиб-нарколог, участок педиаторлары, мәктәп инспекторлары, фельдшерлар |
| 12. | Наркомания белән авыручыларга бәйле кешеләргә социаль-психологик хезмәтләр күрсәтү | март | «Милосердие» үзәге | «Милосердие» үзәге |
| 13. | Мәдәният учреждениеләрендә сәламәтлек клублары булдыру | Ел дәвамында | мәдәният учреждениеләре җитәкчеләре | мәдәният учреждениеләре җитәкчеләре |
| 14. | «STOP! Спайсы" чарасын үткәрү. Әңгәмә барышында балаларга профилактик видеоролик күрсәтелә һәм «STOP! Спайсы" буклетлары таратылачак. | март | авыл җирлекләре | МБУ ММЦ «Яшьләр доньясы» |
| 15. | «Без наркотикларсыз тормыш яклы» дигән викторина үткәрү | март | Потап-Томбарлы авыл китапханәсе | Потап-Томбарлы авыл китапханәсе |
| 16. | Әңгәмәләр, лекцияләр, тренинглар, төркемле дәресләр рәвешендә балигъ булмаганнар белән профилактик эш оештыру | апрель | «Милосердие» үзәге, белем бирү учреждениеләре | «Милосердие» үзәге |
| 17. | «Без тәмәке тартуга каршы» профилактиктик акциясе үткәрү (тәмәке тартуның зарары турында буклетлар тарату) | апрель | Октябрь мәйданы | «Яшьләр дөньсы» КПЯҮ МБУ |
| 18. | Массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү:<br>1. Газетада наркоманияне профилактикалау турында мәкалә. | март, октябрь | массакүләм мәгълүмат чаралары | табиб-нарколог<br><br>табиб-нарколог |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 2. Телевидениедә наркоманияне профилактикалау буенча чыгыш. | | | |
| 19. | «Бәхетле юл», «Без сәламәт яшәү рәвешен сайлыйбыз» профилактик программаларын гамәлгә ашыру аша авыр тормыш хәлендә калган балалар һәм яшүсмерләр белән эшләү | май | «Милосердие» үзәге | «Милосердие» үзәге |
| 20. | Гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары арасында профилактик тикшерүләр үткәрү; наркотик матдәләрне законсыз куллануны рөхсәт итүче затларны ачыклау. Тест-системалар кулланып | Ел дәвамында | белем бирү учреждениеләре | ГАУЗ «Бавлинская ЦРБ» |
| 21. | «Наркотиклар һәм киләчәк буын» темасына әңгәмә үткәрү | июнь | Васькино-Туйралы авыл китапханәсе | Васькино-Туйралы авыл китапханәсе |
| 22. | Ата-аналар белән әңгәмәләр, лекцияләр, тренинглар, төркемле дәресләр рәвешендә профилактик эш башкару | Ел саен | «Милосердие» үзәге | «Милосердие» үзәге |
| 23. | Табиб (психолог) катнашында «Наркотикларның зыяны турында» дигән темага «түгәрәк өстәл» үткәрү, наркотикларның зыяны турында видеоролик күрсәтеп | июнь | «Яшьләр дөньсы» КПЯҮ МБУ | МБУ ММЦ «Яшьлэр доньясы» |
| 24. | «Да здоровью, да мечте, Нет наркотикам, беде!» акциясен үткәрү | Кварталга 1 тапкыр | Поповка авыл китапханәсе | Поповка авыл китапханәсе |
| 25. | Наркоманиягә тартылган социаль куркыныч хәлдәге гаиләләр һәм балигъ булмаганнар турында мәгълүматлар базасына төгәллек кертү | Ел дәвамында | «Баулы үзәк район хастаханәсе» ДАССУ, комиссия по делам несовершеннолет-них | «Баулы үзәк район хастаханәсе» ДАССУ, комиссия по делам несовершеннолетних, отделение социальной защиты, Отдел МВД России по Бавлинскому району |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 26. | "Без дөньяга кызыклы - дөнья безгә кызыклы" исемле мәгълүмат сәгате үткәрү | 2021 елның 26 июле | Потап-Томбарлы авыл китапханәсе | Потап-Томбарлы авыл китапханәсе |
| 27. | Наркоманияне профилактикалауга юнәлдерелгән рәсем конкурслары үткәрү | июль | «Милосердие» үзәге | «Милосердие» үзәге |
| 28. | «Спорт наркотикларга каршы», «Без сәламәт яшәү рәвеше яклы» акциясе үткәрү | август | «Милосердие» үзәге | «Милосердие» үзәге |
| 29. | "Без тормышны сайлыйбыз" дигән мәгълүмат сәгатен үткәрү | 2021 елның 20 августы . | Мортаза авыл китапханәсе | Мортаза авыл китапханәсе |
| 30. | Наркотикларга каршы чаралар үткәрү:<br>- «Аек караш» яшьләр тематик дискотекалары;<br>- наркотикларга каршы тематик кинолекторий;<br>- Яшьләр көне кысаларында “Скажи жизни – да!” акциясе;<br>- "Наркотикларсыз тормыш!" акциясе;<br>- яшүсмерләр һәм яшьләр өчен “Мин сәламәт яшәү рәвеше яклы” ял итү кичәсе;<br>“Тартмаска, эчмәскә, сәламәт булырга!” акциясе | Кварталга 1 тапкыр | СДК, СК, ДК | СДК, СК, ДК белгечләре |
| 31. | Наркотикларга каршы пропаганда һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча мәгълүмат стендлары булдыру | Ел саен | СДК, СК, ДК | СДК, СК, ДК белгечләре |
| 32. | Табиб-нарколог катнашында “Түгәрәк өстәл» үткәрү | Ел саен | СДК, СК, ДК | СДК, СК, ДК белгечләре |
| 33. | «Жизнь в красках», «Планета Земля», «Мы против наркотиков», «Скажи наркотикам – НЕТ!»,«Чума XXI века», «Я за здоровый образ жизни!» темаларына балалар рәсем | Ел саен | СДК, СК,ДК | СДК, СК, ДК белгечләре |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | конкурслары үткәрү | | | |
| 34. | «Наркотикларсыз тормыш» республика акциясендә катнашу | Ел саен | СДК, СК,ДК | СДК, СК, ДК белгечләре |
| 35. | Түбәндәге акцияләр һәм бер тапкыр уздырыла торган чаралар оештыру:<br>-Яшьләр көне кысаларында;<br>- Акцияләр: "Тәмәке урынына конфет ал";<br>"Наркотикларга юк дип әйтик!";<br>"Без СПИДка каршы, безнең белән бул".<br>- Мәктәп лигасының КВН уеннары турнирын үткәрү | Ел дәвамында | - | «Яшьләр дөньсы» КПЯҮ МБУ |
| 36. | «Без тормышны сайлыйбыз!», «Балалар - киләчәгебез!», «Уңышка бер адым!» дигән музыкаль-күңел ачу һәм концерт программалары үткәрү | Кварталга 1 тапкыр | СДК, СК,ДК | СДК, СК, ДК белгечләре |
| 37. | Хокук саклау органнары хезмәткәрләре белән очрашулар үткәрү | сентябрь | «Милосердие» үзәге, Россия Эчке эшләр министрлыгының Баулы районы бүлеге | «Милосердие» үзәге |
| 38. | ДАССУ «Баулы үзәк хастаханәсе» хезмәткәрләре белән очрашулар үткәрү | октябрь | «Милосердие» үзәге, «Баулы үзәк район хастаханәсе» ДАССУ | «Милосердие» үзәге |
| 39. | Массакүләм чаралар аша наркотик чаралар һәм психоактив матдәләр куллануның нәтиҗәләре турында укучылар һәм яшьләр арасында мәгълүмат-аңлату эше оештыру | октябрь | социаль челтәрләр | МБУ ММЦ «Яшьләр доньясы» |
| 40. | "Үзеңне киләчәк өчен сакла!" мәгълүмат сәгате үткәрү | октябрь | Александровка авыл китапханәсе | Александровка авыл китапханәсе |
| 41. | "Наркотиклар", "Үзеңә зыян салма" мультфильмнары күрсәтү | ноябрь | «Милосердие» үзәге | «Милосердие» үзәге |
| 42. | «Без наркотикларсыз дөньяны сайлыйбыз!» | ноябрь | Центральная библиотека | Центральная библиотека |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | акциясе | | г. Бавлы | г. Бавлы |
| 43. | «Жизнь прекрасна - не рискуй напрасно!» мәгълүмат сәгате үткәрү | декабрь | Потап-Томбарлы авыл китапханәсе | Потап-Томбарлы авыл китапханәсе |
| 44. | Фельдшер белән «Һәрвакыт булсын иртәгә» дип исемләнгән очрашу үткәрү | декабрь | Исергаповская сельская библиотека | Исергаповская сельская библиотека |
| 45. | “Яңа буын сәламәт яшәү рәвешен сайлый” спорт ярышлары үткәрү | декабрь | «Милосердие» үзәге | «Милосердие» үзәге |
| 46. | "Мин сәламәтлекне сайлыйм" акциясен үткәрү | 2021 ел | 1нче шәһәр китапханәсе | 1нче шәһәр китапханәсе |
| 47. | «Я выбираю жизнь!» буклетларын әзерләү | 2021 ел | ҮКС китапханәләре | ҮКС китапханәләре |
| 48. | «Мы - за здоровый образ жизни!» дәресләре үткәрү | 2022 ел дәвамында | Баулы шәһәре үзәк китапханәсе | Баулы шәһәре үзәк китапханәсе |
| 49. | «Яңа буын сәламәт яшәү рәвешен сайлый» спорт ярышлары үткәрү | 2022 елның гыйнвары | Фоминовка авыл китапханәсе | Фоминовка авыл китапханәсе |
| 50. | "Сәламәтлекә - "Әйе", наркотикларга - "Юк" китап күргәзмәсе | 2022 ел | Поповка авыл китапханәсе | Поповка авыл китапханәсе |
| 51. | «Наркостоп» мәгълүмат-танып белү сәгатен үткәрү | 2022 елның 19 октябре . | Мортаза авыл китапханәсе | Мортаза авыл китапханәсе |
| 52. | "Без сәламәт яшәү рәвеше яклы" дип исемләнгән буклетлар әзерләү | 2022 ел | ҮКС китапханәләре | ҮКС китапханәләре |

---

“2021-2025 елларга Татарстан Республикасы
Баулы муниципаль районында халыкны
наркотиклаштыруны профилактикалау»
муниципаль программасына кушымта

## “2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында халыкны наркотиклаштыруны профилактикалау» муниципаль программасы максатлары, бурычлары, нәтиҗәне бәяләү индикаторлары

| Төп чаралар аталышы | Башкаручылар | Төп чараларны башкару сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәйләү индикаторлары | Индикаторлар | | | | | Район бюджеты акчалары исәбеннән финанслау, мең сум | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
| Максат: Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында законсыз наркотиклар тарату һәм халыкның медицина максатларыннан тыш куллануы масштабларын киметү | | | | | | | | | | | | | |
| 1нче бурыч. Наркотик матдәләрне куллануны һәм җинаятьләрне киметү | | | | | | | | | | | | | |
| 1.1.Наркотикларның законсыз әйләнешенә һәм законсыз миграциягә каршы көрәшкә юнәлдерелгән ведомствоара оператив-профилактик чаралар үткәрергә | Россия Эчке эшләр министрлыгының Баулы районы бүлеге (килешү буенча) | 2021-2025 еллар | Наркотикларга бәйле тикшерелгән җинаятьләрнең гомуми саныннан авыр һәм аеруча авыр җинаятьләр | 80 | 85 | 90 | 95 | 100 | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.2. Наркотик чаралар, психотроп матдәләр, шулай ук көчле тәэсирле матдәләрнең легаль әйләнештән законлы булмаган булмаган әйләнешкә керүенә юл куймау эшен оештырырга | Россия Эчке эшләр министрлыгының Баулы районы бүлеге (килешү буенча) | 2021-2025 еллар | өлеше, 2020 елда | | | | | | - | - | - | - | - |
| 1.3. "Интернет" челтәре мөмкинлекләрен киңрәк кулланып, ышаныч телефоннарының, гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү буенча кабул итү бүлмәләренең һәркем файдалана алырлык булуын һәм нәтиҗәлелеген арттыруны оештырырга | «ТР БМР Спорт һәм туризм үсеше бүлеге» МКУ, Россия Эчке эшләр министрлыгының Баулы районы бүлеге белән(килешү буенча) | 2021-2025 еллар | | | | | | | - | - | - | - | - |
| 1.4. Наркотикларның законсыз әйләнешенә каршы көрәшне гамәлгә ашыручы хокук саклау органнарына коррупциягә каршы көрәшнең | Россия Эчке эшләр министрлыгының Баулы районы бүлеге (килешү буенча) | 2021-2025 еллар | | | | | | | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| нәтиҗәлелеген арттыру максатларында ышаныч дәрәҗәсен арттыру чараларын гамәлгә ашыру | | | | | | | | | | | | | |
| 1.5. ББУ территориясендә тәмәке эшләнмәләрен куллануны ачыклау максатыннан профилактик чаралар үткәрү | «Баулы үзәк район хастаханәсе» ДАССУ (килешү буенча) Россия Эчке эшләр министрлыгының Баулы районы бүлеге белән(килешү буенча) | 2021-2025 еллар | | | | | | | - | - | - | - | - |
| 2нче бурыч. Наркотикларга бәйле кешеләрне дәвалау һәм тернәкләндерү системасын, туганнарына психотерапевтик хезмәт күрсәтүне камилләштерү | | | | | | | | | | | | | |
| 2.1. Урыннарга чыгып, халыкка медицина консультациясе бирү, шул исәптән дәвалануга мохтаҗларны ачыклау өчен | «Баулы үзәк район хастаханәсе» ДАССУ (килешү буенча) | 2021-2025 еллар | Наркомания белән авыручыларның ачыкланган һәм теркәлгән саны арту, кеше, 2020 елда | 90 | 92 | 95 | 98 | 100 | - | - | - | - | - |
| 2.2. Медицина-социаль тернәкләндерү узган наркомания белән авыручыларны укыту һәм эшкә урнаштыру системасын | «Баулы үзәк район хастаханәсе» ДАССУ (килешү буенча) | 2021-2025 еллар | | | | | | | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| оештырырга | | | | | | | | | | | | | |
| 2.3. Укучыларның, студентларның һәм чакырылу яшендәге затларның наркотик һәм психотроп матдәләр куллану-кулланмавын ачыклау өчен профилактик медицина тикшерүләрен уздыру өчен диагностик тестлар сатып алу | «Баулы үзәк район хастаханәсе» ДАССУ (килешү буенча) | 2021-2025 еллар | | | | | | | - | - | - | - | - |
| 2.4. Тернәкләндерү программаларында катнашучы затларның туганнары белән максатчан эш алып бару | «Баулы үзәк район хастаханәсе» ДАССУ (килешү буенча), «ТР Яшьләр эшләре бүлеге» МКУ, Социаль яклау бүлеге (килешү буенча) | 2021-2025 еллар | | | | | | | 263,0 | 263,0 | 263,0 | 263,0 | 263,0 |
| 2.5. Гаилә кыйммәтләренә, кеше тормышында гаилә ролен багышланган класс сәгатьләре һәм тематик дәресләр үткәрү | «ТР БМР мәгариф бүлеге» МКУ, «ТР Яшьләр эшләре бүлеге» МКУ | 2021-2025 еллар | | 90 | 95 | 100 | 100 | 100 | 996,34 | 996,34 | 996,34 | 996,34 | 996,34 |
| 3нче бурыч. Халыкта сәламәт яшәү рәвеше алып баруны формалаштыру, наркотиклар куллануга тискәре мөнәсәбәт тудыру | | | | | | | | | | | | | |
| 3.1. Мәгариф | «ТР БМР | 2021-2025 | Наркотикларг | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| учреждениеләрендә профилактик эшне оештырырга, шул исәптән түбәндәгеләрне башкарырга: | мәгариф бүлеге» МКУ, «ТР Яшьләр эшләре бүлеге» МКУ | еллар | а каршы программаларда катнашучы ата-аналарның гомуми санынннан агымдагы елда наркотикларга каршы бөтенроссия программалары белән колачланган ата-аналар өлеше, процентларда, 2020 елда | | | | | | 996, 34 | 996, 34 | 996, 34 | 996, 34 | 996, 34 |
| 3.1.1. Хокук бозуларны профилактикалау отрядлары һәм ФОРПОСТ отрядлары эшен координацияләү. Хокук бозуларны профилактикалау отрядлары конкурсын үткәрү | «ТР БМР мәгариф бүлеге» МКУ, «ТР Яшьләр эшләре бүлеге» МКУ | 2021-2025 еллар | | | | | | | 996, 34 | 996, 34 | 996, 34 | 996, 34 | 996, 34 |
| 3.1.2.Гаилә кыймматләренә, кеше тормышында гаилә роленә багышланган класс сәгатьләре һәм тематик дәресләр үткәрү | «ТР БМР мәгариф бүлеге» МКУ, «ТР Яшьләр эшләре бүлеге» МКУ | 2021-2025 еллар | | | | | | | 996, 34 | 996, 34 | 996, 34 | 996, 34 | 996, 34 |
| 3.2. Социаль куркыныч хәлдәге гаиләләр белән эшләүне контрольдә тоту. Имин булмаган гаиләләргә рейдлар. | «ТР БМР мәгариф бүлеге» МКУ, «ТР Яшьләр эшләре бүлеге» МКУ | 2021-2025 еллар | | | | | | | 996, 34 | 996, 34 | 996, 34 | 996, 34 | 996, 34 |
| 3.3. Балаларга карата рәхимсез мөгамәләгә, "хәвеф төркеме" балалары белән ППС | «ТР БМР мәгариф бүлеге» МКУ, «ТР Яшьләр | 2021-2025 еллар | | | | | | | 996, 34 | 996, 34 | 996, 34 | 996, 34 | 996, 34 |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| эшен оештыру. Ата-ана җыелышларына бару, аерым план буенча суицид күренешләрен булдырмау максатында тренинглар, мастер-класслар, уеннар үткәрү | эшләре бүлеге» МКУ | | | | | | | | | | | | |
| 3.4. Яшүсмерләр арасында агрессивлыкны профилактикалау буенча социаль-психологик тренинглар үткәрү | «ТР БМР мәгариф бүлеге» МКУ, «ТР Яшьләр эшләре бүлеге» МКУ | 2021-2025 еллар | | | | | | | 996,34 | 996,34 | 996,34 | 996,34 | 996,34 |
| 3.5 Халыкара СПИД һәм наркоманиягә каршы көрәш көненә багышланган чаралар оештыру һәм үткәрү | «ТР БМР мәгариф бүлеге» МКУ, «ТР Яшьләр эшләре бүлеге» МКУ, «ТР БМР Мәдәният бүлеге» МКУ, Россия Эчке эшләр министрлыгының Баулы районы бүлеге (килешү буенча) | 2021-2025 еллар | | | | | | | 2246,34 | 2246,34 | 2246,34 | 2246,34 | 2246,34 |
| 3.5.1. Баулы районы территориясендә җәмәгать тәртибен | «ТР БМР мәгариф бүлеге» МКУ, | 2021-2025 еллар | | | | | | | 996,34 | 996,34 | 996,34 | 996,34 | 996,34 |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| саклауны тәэмин итү, хокук бозуларны һәм җинаятьләрне булдырмау | «ТР Яшьләр эшләре бүлеге» МКУ | | | | | | | | | | | | |
| 3.5.2. «Школьные службы примирения» проекты эшен оештыру | «ТР БМР мәгариф бүлеге» МКУ | 2021-2025 еллар | | | | | | | 733, 34 | 733, 34 | 733, 34 | 733, 34 | 733, 34 |
| 3.6.Укучылар өчен алкогольле эчемлекләр, спайслар, снюслар куллануның зыяны турында лекцияләр, әңгәмәләр үткәрергә | «ТР БМР мәгариф бүлеге» МКУ, «ТР Яшьләр эшләре бүлеге» МКУ | 2021-2025 еллар | | | | | | | 996, 34 | 996, 34 | 996, 34 | 996, 34 | 996, 34 |
| 3.7. Наркоманияне, токсикоманияне профилактикалау, спайслар, снюслар куллану буенча түгәрәк өстәл артында очрашу:<br>- табиб-нарколог<br>- мәктәп инспекторлары<br>- участок педиаторлары | Белем бирү учреждениеләрендә табиб-нарколог, участок педиаторлары, мәктәп инспекторлары, фельдшерлар | 2021-2025 еллар | | | | | | | - | - | - | - | - |
| 3.8 Сәламәт яшәү рәвешен популярлаштыруга һәм психоактив матдәләр куллануны кисәтүгә юнәлдерелгән җәмәгать фикерен формалаштыру буенча | «ТР Яшьләр эшләре бүлеге» МКУ | 2021-2025 еллар | | | | | | | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| массакүләм мәгълүмат чаралары эшен дәвам итәргә | | | | | | | | | | | | | |
| 3.9.Наркотикларга карата мөнәсәбәтне ачыклау өчен аноним рәвештә анкета тутыру | Социаль яклау бүлеге | 2021-2025 еллар | | 75 | 80 | 85 | 90 | 100 | - | - | - | - | - |
| 3.9.1. Баулы шәһәре һәм Баулы районы командалары арасында мөхтәсибәт кубогына мини-футбол турниры үткәрү | «ТР БМР Спорт һәм туризм үсеше бүлеге» МКУ | 2021-2025 еллар | | 90 | 92 | 95 | 98 | 100 | - | - | - | - | - |
| 3.9.2. Баулы районы оешмалары арасында волейбол турниры үткәрү | «ТР БМР Спорт һәм туризм үсеше бүлеге» МКУ | 2021-2025 еллар | | 95 | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - | - | - |
| 4нче бурыч. Балаларны һәм яшьләрне кызыксынулар буенча түгәрәкләрдә, физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләүгә җәлеп итү өчен шартлар тудыру. Волонтерлар хәрәкәтен үстерү | | | | | | | | | | | | | |
| 4.1. Зарарлы гадәтләргә мөнәсәбәтне ачыклау максатында анкетлау | «ТР Яшьләр эшләре бүлеге» МКУ | 2021-2025 еллар | Балалар һәм яшьләрнең гомуми санында кызыксынулар буенча түгәрәкләрдә, физик культура һәм спорт түгәрәкләрендә даими шөгыльләнүч | 80 | 84 | 90 | 95 | 100 | 263,0 | 263,0 | 263,0 | 263,0 | 263,0 |
| 4.2. Түбәндәге чараларны һәм акцияләрне үткәрү:<br>- Яшьләр көне кысаларында заманча яшьләр субкультуралар фестивале;<br>- түгәрәкләр үткәрү; | «ТР Яшьләр эшләре бүлеге» МКУ | 2021-2025 еллар | | | | | | | 1 000,0 | 1 000,0 | 1 000,0 | 1 000,0 | 1 000,0 |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| - «Возьми конфету вместо сигареты» акциясе,<br>- «Скажем наркотикам НЕТ!»;<br>- «Мы против СПИДа будь с нами»;<br>- Мәктәп лигасының КВН уеннары турнирын үткәрү;<br>-флешмоб үткәрү;<br>- "СТОП-ВИЧ" акциясе | | | е, волонтерлык эшчәнлегендә катнашучы балалар һәм яшьләр өлеше, процентларда, 2020 елда | | | | | | | | | | |
| 4.3.Яшьләрне массакүләм яшьләр күңел ачу чаралары уздыруга җәлеп итү | «ТР Яшьләр эшләре бүлеге» МКУ, «ТР БМР Мәдәният бүлеге» МКУ | 2021-2025 еллар (согласно графику проводимых мероприятий) | | | | | | | 1 461,0 | 1 461,0 | 1 461,0 | 1 461,0 | 1 461,0 |
| 4.4. Халыкара балаларны яклау көненә багышланган чаралар оештыру һәм уздыру | «ТР БМР мәгариф бүлеге» МКУ, «ТР Яшьләр эшләре бүлеге» МКУ, «ТР БМР Мәдәният бүлеге» МКУ | 2021-2025 еллар (1 июня) | | | | | | | 2194,34 | 2194,34 | 2194,34 | 2194,34 | 2194,34 |
| 4.5. «Самостоятельные дети» проекты кысаларында чаралар үткәрү: “Сообщи, где | «ТР БМР мәгариф бүлеге» МКУ, «ТР Яшьләр | 2021-2025 еллар | | | | | | | 2194,34 | 2194,34 | 2194,34 | 2194,34 | 2194,34 |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| торгуют смертью», «Будь готов! Скажи, нет!», «Россия без табака», «Легалка не пройдет», «Будь здоровым! Танцуй!», «Поделись улыбкой» | эшләре бүлеге» МКУ, «ТР БМР Мәдәният бүлеге» МКУ | | | | | | | | | | | | |
| 4.6. Наркотиклар куллану фонында балигъ булмаганнарга карата көч куллануны профилактикалау", «ИМЯ беды – наркотики» пресс-конференциясе | Социаль яклау бүлеге (килешү буенча) | 2021-2025 еллар | | | | | | | - | - | - | - | - |
| 5нче бурыч. Наркотикларга каршы эшчәнлекне оештыру, норматив-хокукый һәм методик тәэмин итүне камилләштерү | | | | | | | | | | | | | |
| 5.1.Хокук бозуларны профилактикалауның барлык субъектлары катнашында тематик түгәрәк өстәлләр оештыру | Россия Эчке эшләр министрлыгының Баулы районы бүлеге (килешү буенча) | 2021-2025 еллар | наркотикларга каршы юнәлештә квалификация күтәрү курсларында һәм семинарларда укыган белгечләрнең гомуми санында агымдагы елда наркотикларг | 80 | 90 | 100 | 100 | 100 | - | - | - | - | - |
| 5.2. Балигъ булмаганнарның дәрестән тыш вакытта мәшгульлеге мониторингы | «ТР БМР мәгариф бүлеге» МКУ | 2021-2025 еллар | | | | | | | 733, 34 | 733, 34 | 733, 34 | 733, 34 | 733, 34 |
| 5.3. Массакүләм мәгълүмат чаралары: 1) газетага мәкалә: наркоманияне, | «Баулы үзәк район хастаханәсе» ДАССУ (килешү | 2021-2025 еллар | | | | | | | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| токсикоманияне, спайслар, снюслар куллануны профилактикалау;<br>2) Телевидениедә чыгыш ясау: наркоманияне, токсикоманияне, спай-слар, снюслар куллануны профилактикалау | буенча) | | а каршы юнәлешле семинарларда һәм курсларда белем алган белгечләрнең өлеше, процентларда, 2020 елда | | | | | | | | | | |
| 5.4. Белем бирү учреждениеләрендә хокукый тематикага («балалар ышаныч телефоны») стендлар булдыру | «ТР БМР мәгариф бүлеге» МКУ | 2021-2025 еллар | әзерләнгән буклетлар өлеше, процентлар, 2020 елда | 70 | 75 | 80 | 85 | 90 | 733, 34 | 733, 34 | 733, 34 | 733, 34 | 733, 34 |
| 5.5. Рәсми сайтларга «Үлем белән кайда сату итүләрен хәбәр ит» бөтенроссия акциясе турында хәбәр урнаштыру («ышаныч телефоннары» номерларын күрсәтеп) | «ТР Яшьләр эшләре бүлеге» МКУ | 2021-2025 еллар | | 80 | 86 | 90 | 92 | 95 | 211, 0 | 210, 0 | 210, 0 | 210, 0 | 210, 0 |